***Мөхәммәтҗанов Ильяс***

# «ХӨСРӘҮ ВӘ ШИРИН" ПОЭМАСЫНЫҢ ТАРИХЫН КҮЗӘТҮ ҺӘМ ПРОБЛЕМАНЫҢ КУЕЛЫШЫ

XIII–XIV йөзләрдә Идел буе төрки әдәбияты зур тизлек белән үсә башлаган. Аеруча поэзия зур уңышларга ирешкән. Шагыйрьләр фарсы телендә язылган гуманистик әсәрләргә аеруча зур игътибар белән караганнар. Күп кенә әсәрләрне тәрҗемә итәргә керешкәннәр. Шундый әсәрләрнең берсе – "Хөсрәү вә Ширин" поэмасы.

"Хөсрәү вә Ширин" поэмасын 1180 елда бөек Әзәрбәйҗан шагыйре Низами Гәнҗәви иҗат иткән. Ике йөз елга якын вакыт үткәннән соң, 1342 елда, Идел буе шагыйре Котб фарсы телендә язылган бу әсәрне төрки телгә, ягъни безнең борынгы әдәби телебезгә тәрҗемә иткән. Ундүртенче гасырда Ак Урдада иҗат ителгән "Хөсрәү вә Ширин" поэмасы озак гасырлар төрки халыкларга аз билгеле булып, тулы күчермәсе тик XX гасырда гына Европа китапханәләрендә табылган гаҗәеп бер шигъри тезмә әсәр. Бу тезмәле романның авторы үзен Котб дип атый һәм әсәрне Низами әсәренә нигезләнеп язылганлыгын әйтә. Чыннан да, шигъри романда күпчелек урыннарда фарсы телендә язган Әзәрбәйҗан шагыйре Низами Гәнҗәвинең "Хәмсә"сенә кергән "Хөсрәү вә Ширин"не тәрҗемә итү күзәтелә. Ләкин Котбның "Хөсрәү - Ширин"е гади тәрҗемә генә түгел. Аның шигырь белән тәрҗемә ителүен, текстның байтак өлеше оригиналь эчтәлекле булуын, Низами поэмасының кайбер урыннары кыскартылуын, үзгәртелүен искә алганда, поэманы автор әсәре дип тә карарга мөмкин. Үзенең лексик һәм грамматик үзенчәлекләре буенча ул татар һәм уйгур телләре арасында торган һәм үзендә угыз телләре элементлары да булган шивә телен тәшкил итә.

Авторның шәхесенә килгәндә, аны Ак Урда ханы Тәнибәк сараена төньяктан - Болгардан килгән дип уйларга да нигез бар. Котб үзен Ак Урдага ерак юл йөреп килгәнлеген әйтә. Тик менә, кызганычка каршы, каян килгәнлеге турында мәгълүмат бирми. Аның тел үзенчәлекләре исә кыпчаклардан булуына ишарә итә. Күренекле галим Г.Таһирҗанов Котбны чыгышы белән Болгар илендәге искил кабиләсеннән дип күрсәтә. Искилләр исә IX гасырда Уйгурстаннан күчеп килеп, болгарларга кушылып яши башлаган халык булган.

Тәрҗемә укымышлылар арасында шул заманда ук шактый танылган булса кирәк. 1382 елда Идел буе югары катлау вәкиле Алтын Бога, үзенең укы-

мышлы колы Бәркә Фәкыйһ белән Мисырга, Искәндәрия шәһәренә килә. Искәндәриядә торганда Бәркә Фәкыйһ Котб тәрҗемә иткән “Хөсрәү вә Ширин” поэмасын күчереп яза. Котбның үз кулы белән язылган нөсхә сакланып калмаган, безгә аның тик 1383 елда Бәркә Фәкыйһ күчереп калдырган нөсхәсе генә килеп җиткән. Бу кулъязма нинди юллар беләндер Парижга-Франциянең Милли китапханәсенә эләккән. Хәзерге көндә әсәрнең безгә билгеле булган нөсхәсе Парижның Милли китапханәсендә 312нче номер белән билгеләнеп саклана. Кулъязма 238 биттән гыйбарәт, һәр биттә уртача 21 бәет. Китапның 4-233 битләрендә Котб әсәре урнаштырылган. 233-236 битләрдә – Бәркә Фәкыйһ шигырьләре. Кулъязманың башка өлешләренә төрле кул белән гарәпчә, төркичә язмалар теркәлгән. Алар арасында хәдисләр, сан таблицалары, шигырьләр һәм башка характердагы юллар бар. 1-3 һәм 237-238 битләрдәге язмалар Котб һәм Бәркә Фәкыйһ иҗатлары белән бәйләнмәгән. Әмма алар арасындагы аерым шигырьләр әдәбият тарихы өчен билгеле бер әһәмияткә ия. Мәсәлән, 2 биттәге дүртьюллык робагый үрнәге буларак характерлы. Кыскасы, Париж нөсхәсенең язылу рәвеше XIX йөз төрки-татар язма истәлекләре графикасыннан әллә ни аерылмый. Безнең карашыбызча, бу күренеш табигый да . Чөнки күчерүче – Алтын Урда – Мисыр мәдәни традицияләрендә тәрбияләнгән кеше, Мәхмүд Болгари, Сәйф Сараиларның кече чордашы. Үз туган теленнән тыш, ул гарәп-фарсы телләрен яхшы белгән. Кулъязманың 283нче битендә бер үк эчтәлекле ике робагый бар. Аларның беренчесе -- гарәпчә, икенчесе – фарсыча. Димәк, Бәркә бу телләрдә шигъри әсәрләр дә иҗат иткән. “Хөсрәү вә Ширин” күчермәсе һәм китап ахырына теркәлгән 51 бәетлек шигыре Бәркәнең билгеле бер поэтик таланты булу хакында да сөйли. Дөрес, әле аның оригиналь юлларында урынсыз кабатланулар, ритмик төгәлсезлекләр бар. Әмма шуңа да карамастан, Бәркәнең шигырьләре дөньяви характерда булулары, аерым тарихи мәгълүматларны үз эченә алулары, гадилекләре белән игътибарга лаек. Әмма, шуңа да карамастан, Котб әсәрен ул намус белән күчергән. Париж нөсхәсенең яхшы сыйфатлы чыгуында Бәркә Фәкыйһның гыйльми һәм иҗат эшләре белән шөгыльләнүе дә уңай йогынты ясаган.

Бәркә Фәкыйһ күчермәсе төрле кулларда һәм урыннарда булган. Нөсхәдәге язмалар нәкъ әнә шул хакта сөйли. Кульязманың кайчан, нинди юллар белән Франциягә эләгүе билгесез. Безнең уебызча, нөсхә XVII гасырларга кадәр Якын Көнчыгышта сакланган булырга тиеш. Чөнки Көнбатыш Европада Шәрекъ кулъязмалары белән ныклап кызыксыну аларны туплау, нигездә, XVII йөздән генә башлана. Кайвакыт “Хөсрәү вә Ширин” үз дәверендә укылмаган, таралмаган дигән фикер белән очрашырга туры килә. Моңа төп дәлил итеп әсәрнең бер генә нөсхәдә саклануы китерелә. Әмма бу мәсьәлә ачыклауны сорый. Беренчедән, Алтын Урда чоры әдәбиятын күздән кичергәндә анда Котб иҗаты белән охшаш, аваздаш моментларны сиземләве һич тә кыен түгел. Алар тәрҗемә принципларында да, тел-сурәтләү чараларын куллануда да, идея-мотивларның чагылышында да ачык күренә. Димәк, “Хөсрәү вә Ширин” әсәре үзеннән соңгы әдәбиятта эзсез калмаган. Икенчедән, поэманың бер күчермәсе нининдидер юллар белән, төрки-кыпчак мәдәниятенең мөһим үзәге – Мисыр – Сүриягә эләгә. Укучыларның ихтыяҗын күздә тотып, Бәркә Фәкыйһ аның яңа нөсхәсен эшли. Өченчедән, әсәрнең бер генә данәдә сакланып калуы, гасырлар буена онытылып торуы әле аның укылма-

вына, таралмавына ышанычлы дәлил була алмый. Бәлки, аның нөсхәләре күп булып, юкка чыккандыр, бәлки, кайберләре тикшерүчеләрне көтә торгандыр. Таш калаларны җир белән тигезләгән гасыр афәтләренең “рухи культура җимешләренә, ягъни китапларга, язма документларга карата тагы да шәфкатьсезрәк булуы үзеннән – үзе аңлашыла[1]. Шуңа күрә элекке дәверләрнең безгә мәгълүм ядкярләрен олы мәдәният учагыннан читкә чәчрәгән аерым очкыннар, бөртекләр дип кенә кабул итәргә кирәк[2]. Галимнәрнең тырышлыгы ярдәмендә әнә шул читкә чәчрәгән, вакытлыча онытылган “бөртек”ләрнең берсе – “Хөсрәү вә Ширин”не укучыларга кабат җиткерүдә шактый эш башкарылды. Соңгы елларда текстның аерым өлешләре төрле китап-журналларда басылып чыкты.

40-50 елларда “Хөсрәү вә Ширин” кулъязмасын текстологик һәм лингвистик яктан поляк галиме Ананияз Зайончковский ныклап өйрәнә. Аның тикшеренү нәтиҗәләре төрле илләрдәге һәм телләрдәге гыйльми язмаларда, журналларда басылган[3]. Алар арасында русчалары да бар. А.Зайончковский эшчәнлегенең иң мөһим ягы шунда: ул тюркологиядә беренче булып “Хөсрәү вә Ширин” кульязмасының тулы фотокүчермәсен, транскрипциясен һәм сүзлеген бастырып чыгарды. Өч китаптан торган бу хезмәт 1958-1961 елларда дөнья күрде. 1958 елда А.Зайончковскийның мәшһүр китаплары чыкты. Әйтергә кирәк, “Хөсрәү вә Ширин”нең Варшава басмасы – хәзергәчә иң ышанычлы һәм гыйльми басма 1969 елда Котб һәм Бәркә Фәкыйһ әсәрләре Х.Госман һәм З.Максудова тарафыннан Казанда нәшер ителде. Ике кисәктән торган бу басма А.Зайончковский китабындагы фотокопиянең “машинкада төгәл күчермәсе”. Дөрес, әле анда бик үк “төгәл” булып җитмәгән урыннар бар: аерым сүзләрне укуда, язуда кайбер кимчелекләргә юл куелган. Аларның күпчелеге төрткеле хәрефләрне бутап басу нәтиҗәсендә киткән. Хәзер А.Зайончковский китапларын табу җиңел түгел, тапкан очракта да фотокүчермә белән эш итү уңайсыз. Шуңа күрә Казан басмасы студентларны һәм гыйльми җәмәгатьчелекне Котб әсәренең үзе белән таныштыру ягыннан игътибарга лаек.

Профессор А.Зайончковский Котбның романын Әзәрбәйҗан шагыйре Низаминың фарсыча язылган романы белән тулысынча чагыштырып чыгып, төрки телдә язылган Котб варианты – Низами романының тәрҗемәсе дигән төпле нәтиҗәгә килә.

Романның телен һәр яклап тикшереп, өйрәнеп чыкканнан соң профессор А.Зайончковский да, күренекле рус тюркологы А.Самойлович та, “роман Алтын Урдадагы берничә әдәби язма истәлекләрнең берсе” дигән фикергә киләләр. А.Самойлович романның үзен Алтын Урдада язылган, ә күчермәсе, беркадәр язылып, Мисырда эшләнгән, дип саный[4]. А.Зайончковский, күчермә бозып бозып бирелмәгән[5], ди.

1973 елда “XIV аср Хоразм едномалари” исемле китапта “Хөсрәү вә Ширин”нең үзбәк басмасы дөнья күрде. Аны нәшрияткә Ә.Фазыйлов әзерләгән. Текстлар басмада хәзерге үзбәк графикасында биреләләр, фәнни аңлатмалар, сүзлек юк. Бары тик Котб әсәре хакында кечкенә генә мәкалә урнаштырылган (129-131 битләр). Ташкент басмасы тулы басма түгел. Ни сәбәптәндер, поэманың әдәби-тарихи яктан мөһим булган багышлау өлешләре (4-16 битләр, барлагы 239 бәет) читтә калган. Шулай ук 229-232 нче битләрдәге соңгы бүлек тә китапта юк. Гомумән, поэма үзбәк басмасында 304 бәеткә кыскартып бирелгән.

Казан басмасына хас кимчелекләр

Э.Фазыйлов китабында да җибәрелгән. Әмма алар үзбәк басмасында чагыштырмача күбрәк очрый. Э.Фазыйлов текстны хәзерге үзбәк фонетик кануннарына нигезләп бирергә омтыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, сузык авазларны язуда шактый гына төгәлсезлекләргә, бәхәсле моментларга юл куелган.

Теге яки бу дәрәҗәгә кимчелекләр булуга да карамастан, Казан, Ташкент басмалары Котб әсәре белән укучыларны таныштыруда билгеле бер әһәмияткә ия. Әмма алар безнең хәзерге ихтыяҗны тулысынча канәгатьләндерә алмыйлар. Бүгенге фән һәм мәдәният үсеше "Хөсрәү вә Ширин"не, Варшава басмасы тибында тулы, гыйльми итеп, үзебезнең илдә нәшер итүне таләп итә.

Татар әдәбияты гыйлемендә "Хөсрәү вә Ширин" әсәрен өйрәнә башлау Ә.Н.Нәҗип исеме белән бәйле. Ул әлеге язма истәлек турында үзенең 1957 елда "Совет әдәбияты" журналында басылып чыккан күләмле мәкаләсендә яза[6]. Галим тексттагы тел үзенчәлекләрен әтрафлы тикшерүгә хезмәтләр багышлый[7]. Аның тарафыннан 1979 елда Котб әсәре материаллары низезендә XIVйөз төрки телләренең дүрт китапка исәпләнгән тарихи-чагыштырма сүзлекнең беренче томы нәшер ителә[8]. XIV гасырдагы төрки телләрнең тарихына нисбәтле китабында да ядкяргә тиешле урын биргән[9].

Әдәбиятта Хөсрәү – Ширин темасын башлап өйрәнүчеләрнең берсе профессор Г.Т.Таһирҗанов булды. Ул Идел буе шагыйре Котбның "Хөсрәү вә Ширин" поэмасының язылу тарихын, язма истәлекләренең стилен, аның әдәби һәм тел үзенчәлекләрен Әзәрбәйҗан классигы Әбу Мөхәммәд Ильяс ибне Йосыф Низами Ганҗәвинең (1141-1209) шул исемдәге әсәре белән чагыштырып тикшерә[10]. Галим әлеге юнәлештә башкарган бәрәкәтле эшенең нәтиҗәләрен үзенең башка хезмәтләрендә дә киң яктыртты[11]. Г.Т.Таһирҗановның бу хезмәте тирәнлеге, фактик материалга һәм теоритик гомумиләштерүләргә бай-лыгы белән Котбка багышланган тикшеренүләр арасында иң күренеклесе булып кала. Г.Таһирҗанов шагыйрь иҗатын өйрәнүне хәзер дә дәвам итә. Аның татар әдәбияты тарихының катлаулы мәсьәләләрен яктыртуга багышланган мәкаләләре арасында, мәсәлән, Котбка мөнәсәбәтле үзенчәлекле фикерләр бар[12].

Әмир Нәҗип мондый фикер белдерә: "Бер-ике әсәрдә дә сюжет һәм аның үстерелеше бер үк төрле, ләкин тәрҗемә процессында әсәргә шактый күп үзгәрешләр кертелгән, шунлыктан роман яңа туфракта, фактик яктан нәзыйрага әверелгән. Димәк, ул Низами романына җавап рәвешендә язылган, ярыморигиналь мөстәкыйль роман". Шуңа якын фикерне Х.Миңнегулов күәтли: "Низами поэмасында Котб Алтын Урда төрки укучысының ихтыяҗына, зәвыгына, үзенең иҗаты максатларына туры килешле", - ди. Әлеге язма истәлекне өйрәнү юнәлешләрендә профессор Х.Ю.Миңнегулов Котбның тормышы һәм иҗади эшчәнлеге турында 1976 елда студентлар өчен уку ярдәмлеге төзеп бастыра, аңа башка хезмәтләрендә дә мәгълүм дәрәҗәдә урын бирә[13].

Әдәбиятчы Н.Ш.Хисамов исә Котбның урта гасыр төрки поэтикасын аңарчы күрелмәгән биеклеккә күтәрүен билгели[14].

Е.Э.Бертельс — "Хөсрәү вә Ширин" сюжетына җитди игътибар биргән галимнәрдән. Мәсәлән, ул Низаминың иҗади эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган бер хезмәтендә бу хосустагы Византия, Сүрия һәм гарәп хроникаларын билгели, риваятьнең Фирдәүси поэмасында үзләштерелү үзенчәлегенә, Әзәрбәйҗан шагыйренең шул

исемдәге әсәренә әдәби анализ ясый[15]. Е.Э.Бертельс үзенең хезмәтләрендә "Хөсрәү вә Ширин" – XIV йөздә Алтын Урда җирлегендә барлыкка килгән дөньяви эчтәлекле әсәрләрнең әүвәлгеләреннән[16], - ди. Түбәндәге хезмәтендә Е.Э.Бертельс үзенең мәкалә хезмәтләрендә шагыйрь һәм аның әсәре хакында кайбер фикерләр әйтә[17]. Ул үзенең китабында "Хөсрәү вә Ширин" сюжетының билгеле бер реаль җирлеге булуын искәртә.

Хөсрәү-Ширин темасын колачлы һәм җентекле тикшерүләр арасында Г.Й.Алиевның хезмәтләре шулай ук билгеле урын алып тора. Ул әлеге ике тарихи шәхес турындагы риваятьләрне, Низаминың "Хөсрәү вә Ширин" һәм Әмир Хөсрәү Дәһләвинең "Ширин вә Хөсрәү" әсәрләрен чагыштырма планда өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклый[18]. Ул аны алга таба тулыландырып һәм киңәйтеп башкарып, аерым монография итеп бастыра[19]. Шәрекъ әдәбиятында Хөсрәү – Ширин темасын этрафлы өйрәнүгә багышланган хезмәтләрдән янә Г.Бегделинең күләмле китабын билгеләп үтү зарур[20]. Хосусан, анда Низамига кадәр булган риваятьләргә анализ ясала, сюжетның фарси, төрки (үзбәк, төрек, әзәрбәйҗан) әдәбиятларында алган урыны конкрет үрнәкләр нигезендә тәфсилле тикшерелә. Я.Әкман хезмәтләрендә дә "Хөсрәү вә Ширин" турында кызыклы гына мәгълүмат табарга мөмкин[21]. Профессор В.Х.Хаков үзенең хезмәтләрендә Котб әсәренең тел – стиль үзенчәлекләрен анализлый[22]. 1992-1993 елларда Р.Г.Әхмәтҗанов "Мирас" журналында текстның хәзерге әдәби телдә тәрҗемәсен эшләп бастырды[23]. "Хөсрәү вә Ширин"нең шигырь төзелеше мәсьәләсе поэтика белгече Х.Р.Курбатов хезмәтләрендә дә карала[24]. "Татар поэзиясе антологиясен"дә поэманың кыскартылган өлеше генә урын алган[25]. Соңгы елларда "Хөсрәү вә Ширин" мәктәп дәреслекләренә дә кертелде[26]. "Хөсрәү вә Ширин" Урта Азия филологларының да игътибар үзәгендә булганлыгын билгеләп үтү урынлы булыр. Н. М. Маллаев үзе төзегән "Үзбәк әдәбияте тарихы" дигән ике томлык китапның беренчесендә әсәрне анализлауга шактый урын бирә[27]. Шундый биш томлык хезмәтнең беренче томында шулай ук әлеге ядкяр турында киң мәгълүмат урнаштырылган[28].

Үзбәк теле тарихына мөнәсәбәтле язылган хезмәттә дә Котб иҗаты материаллары киң файдаланылган[29]. Әсәрнең берникадәр өлеше 1986 елда нәшер ителгән "Өч былбыл гөлшаны" дигән китапта да урын алган[30]. Шагыйрь һәм аның иҗади эшчәнлеге турында Х.Хәмидов[31], Ж.Шәрипов[32], С.Иркенов[33], Г.Ганиханов[34] хезмәтләрендә шулай ук кызыклы гына мәгълүмат табарга мөмкин. Шунысы да мәгълүм булсын, кайбер үзбәк галимнәре Котбны һәм аның иҗатын фәкать Харәзем төбәге белән генә бәйләп аңлатырга тырышалар[35]. Андый фикерләрнең нигезсез булуын үз вакытында профессор Г.Т.Таһирҗанов язып чыккан иде[36]. "Хөсрәү вә Ширин" казакъ әдәбияты һәм теле гыйлемендә дә мәгълүм дәрәҗәдә өйрәнелә. Әлеге мөнәсәбәттә, мәсәлән, югары уку йортлары өчен төзелгән уку әсбабын, Ә.Кәримов, Б.Сагындыковның кайбер хезмәтләрен күрсәтеп үтәргә мөмкин[37]. А.М.Ибәтов 1974 елда ядкярнең сүзлеген төзеп бастыра[38]. Икенче бер тел галиме М.Б.Сабиров тарафыннан поэма телендәге реликт формалар тикшерелде[39]. Ядкяр татар фәлсәфәсе тарихы яссылыгында да өйрәнелә[40].

1962 елда "Хөсрәү вә Ширин" иҗат ителүгә 620 ел тулу уңае белән әдәбиятчы Х.Госман матбу-

гат битләрендә әсәр турында чыгыш ясый[41]. Галим редакциясендә 1970-71 елларда әсәрнең гарәп графикасында башкарылган тулы тексты офсет ысулы белән нәшер ителә[42]. Ул икенче бер китабында да поэмага күләмле урын бирә[43]. Поэманың гарәп хәрефләрендә зур булмаган тексты студентлар өчен 1965 елда дөнья күргән уку ярдәмлегендә дә бар[44].

Ядкярнең теле мәсьәләсенә килгәндә исә, профессор Ф.М.Күпрелезадә аның Алтын Урда әдәби телендә язылганлыгын белдерә[45]. Ә икенче бер төрки галиме Н.Хаҗи Әмин углы текстта чыгтай элементларының өстенлек алуына ишарә ясый[46]. "Хөсрәү вә Ширин" поэмасының тюркологиядә төрле аспектларда өйрәнеленү дәрәҗәсе турында Р.Ф.Исламов хезмәтләреннән дә табарга мөмкин[47]. Н.М.Исмагыйлева фарси "Шаһнамә"дә һәм Низаминың "Хөсрәү вә Ширин" әсәрендәге Хөсрәү сүрәтләнешен тикшереп, әлеге образны Фирдәүси шаһнәмәгелек өслүбендә, ә әзәрбәйҗан әдибе аны динамик үсештә күрсәтүен билгеләде[48]. Төрек әдәбиятчысы Н.Банарлы Котб әсәрләренең ярыморигиналь, ярымиярү характкерында булуына басым ясый[49]. Х.Г.Кёр – оглы Котб поэмасын тәрҗемә дип карауга каршы төшә һәм аны мөстәкыйль әдәби әсәр дип атый[50].

"Хөсрәү вә Ширин" поэмасы үзеннән соңгы әдәби үсешкә зур йогынты ясый. Анда төрле телләрдә 40 тан артык нәзыйрә генә языла. Болар арасында иң күренеклеләре – фарсы-һинд шагыйре Әмир Хөсрәү Дәһләви (1253-1325) һәм төрки-үзбәк әдибе Галишер Нәваи (1441-1501) әсәрләре. "Ширин вә Хөсрәү" һәм "Фәрһад вә Ширин" дип исемләнгән бу поэмалар 1299, 1484 елларда тәгәлләнә. Филология фәннәре докторы Ф.Урманчеев "Хөсрәү вә Ширин"дә ислам тәгълиматы һәм мифологиясе тәэсире ярыйсы ук көчле булып, поэманың рухи нигезен тәшкил итә[51], - ди. Котб һәм аның әсәре хакында аерым мәгълүматлар татар, үзбәк, төрки әдәбият тарихларында совет һәм чит ил тюркологларының төрле хезмәтләрендә дә очрый.

XIV йөздә иҗат ителгән "Хөсрәү вә Ширин" ядкяренә, аны тудырган авторның иҗатына галимнәр моннан соң да мөрәҗәгать итәчәкләр, әлбәттә. Чөнки бу әсәр, фәндә соңрак мәгълүм булуына карамастан, тюркологиядә ныклы урын яулап алды – аның мөһим әдәби әсәр булуы һәм гаять бай телле истәлек икәнлеге хәзер бернинди бәхәс тудырмый. Хәтта гомумән урта гасыр төрки телле әдәбиятларны, бигрәк тә Алтын Урдадагы әдәби процессны күзаллау өчен Котбның "Хөсрәү вә Ширин" поэмасыннан башка бер адым да атлап булмаячак. Менә шуңа күрә бу истәлек белән киң җәмәгатьчелекне якыннанрак таныштыру эше безнең өчен дә бик актуаль[52].

Котб мирасының әһәмиятен билгеләгәндә, тарихи-сәяси яисә милли-этник һәм саф әдәби факторлар белән генә дә чикләнергә ярамый. Бөек Низами Гәнҗәвинең мирасы кебек үк, Котб иҗаты да зур әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләрне күтәрүе белән әһәмиятле. Һәр ике "Хөсрәү вә Ширин"дә дә гаделлек, хакыйкатькә тугрылык, инсафлылык, намуслылык мәсьәләләре беренче планга куела: мәхәббәт кебек көчле хис тә тар шәхси омтылышларга түгел, ә гаделлек, кешелеклелек принципларына буйсынырга тиеш дигән фикер уздырыла. Мәсәлән, Низами үзенең "Ләйлә вә Мәҗнүн" дигән әсәрендә мәхәббәт хисе акылга хаким булса, кешене җәмгыятьтән аера, аның кешелеген югалта дигән фикерне раслый. Әмма Котб тәрҗемә өчен сайлаган "Хөсрәү вә Ширин"дә исә мәхәббәт акылга буйсынган; сөю хисе нинди генә көчкә ия булса да, акыл аны үз кулында тота, гашыйкка намусын югалтырга,

шәхси теләкләренә бирелеп, йөз суын түгәргә, кешелеклек сыйфатларын җуярга ирек бирми. Киресенчә, акылын, намусын, саклаган кеше генә чын мәхәббәт өчен көрәшкә сәләтле, ә мондый иҗтимагый конкрет, акылга муафикъ мәхәббәт исә власть көче белән мәгърур патшаны да начар холыклардан арындыра ала... Низами әсәренең шушы сыйфатына игътибар итсәк, Котбның иҗтимагый йөзе тагы да ачыклана төшә.

Поэмада куелган икенче бик мөһим мәсьәлә – ул эшне, хезмәтне, һөнәрне мактау; эш, хезмәт, һөнәр әһелләрен мактау юлы белән аларның байлык, вөҗданлылык, гаделлек җәһәтеннән хаким сыйфатлардан аерылып торуын күрсәтү. Тәхет иясе Хөсрәүгә ташчы-һөнәрче Фәрһадны каршы кую чоры өчен хөкем сөрүче сыйныфка хезмәт ияләрен каршы кую булып яңгырый. Хөсрәү – матур, акыллы, гыйлем-хикмәт өйрәнгән, сугыш һөнәрен яхшы белгән, арслан үтерерлек көчкә ия батыр кеше. Әмма ул власть көче белән исергән мәгърур, эгоист, башкаларны үзенә кол итәргә омтылган, хатын-кызны нәфес ихтыяҗларын үтәү өчен генә яратылган дип инанучы, Ширин әйтмешли, икейөзле, ике сүзле, көндәшен явызларча үтерүче, мәкерле, залим бер зат. Аның каршысы булган Фәрһад исә эчкерсез, намуслы тугры сүзле, дөрес табигатьле, чын күңелдән сөя белүче, үз эшенә фидакярләрчә бирелгән чын рәссам. Боларны каршы кую Низами иҗатында очраклы булмаса, Котбның шушы сюжетны сайлап, аны үз ана телендә яңгыратуы, кайбер фикерләрне социаль мотивларны көчәйтеп, кискенләштереп җибәрүе дә очраклы түгел, әлбәттә. Чыннан да Котб поэмасы, гәрчә ул ярыморигиналь, ярымтәрҗемә әсәр булса да, үзенең идея юнәлеше художество байлыгы белән үзеннән соңгы төрки-татар әдәбиятына зур йогынты ясады. С.Сараи, Мөхәммәдьяр кебек шагыйрьләр фарсы әдәби казанышларын үзләштерүдә Котбка хас иҗат принциплары белән эш иттеләр. "Хөсрәү вә Ширин" әсәре Алтын Урда әдәби теле формалашуда хәлиткеч роль уйнады.

***ПРИМЕЧАНИЕ***
***1. Казан утлары. – 1975. - № 8. – С. 150.***
***2. Фазылов Э. Староузбекский язык. Хорезмейские памятники XIV века. Том II. Ташкент, 1971, с. 12-13.***
***3. Zajączkowski A. Zabutek jezukowy ze Zlotej Ordy "Husrev Sirin" Qutba // RO. – Warzsawa, 1954. – XIX т. – б. 45-127.***
***4. Самойлович А.Н. К истории литературного среднеазиатского турецкого языка. // Сборник научных статей / Мир-Али-Шир. – Л., 1928. – б. 6.***
***5. Совет әдәбияты. – 1957. - № 12. – С. 79.***
***6. Нәҗип Ә.Н. Татар әдәбиятының һәм әдәби теленең кайбер онытылган язма истәлекләре турында // Совет әдәбияты. – 1957. – № 12. – С. 79-80.***
***7. Наджип Э.Н. "Хосрау и Ширин" Кутба и его язык. // Сборник научных статей / Тюркологический сборник. К шестидесятилетию Андрея Николаевича Кононова. – М.: Наука, 1966. – С. 80-91.***
***8. Наджип Э.Н. Историко – сравнительный словарь тюркских языков XIV века на материале Хосрау и Ширин" Кутба. – М.: Гл. ред. восточн. литературы, 1979. – Книга 1. – С. 479.***
***9. Наджип Э.Н. Исследования по истории тюркских языков XI–XIV вв. – М.: Наука, 1989. – С. 127-136.***
***10. Тагирджанов А.Т. "Хосров и Ширин" Кутба: Дис. … канд. филол. наук. – Ташкент, 1946. – 252с.***
***11. Таһирҗанов Г.Т. Тарихтан – әдәбиятка. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – Б. 95-159; Котбның "Хөсрәү вә Ширин" әсәре / Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. – Т. 1. – Б. 170-196.***
***12. Казан утлары. – 1975. - № 7, 8, 10.***

13. Миңнегулов Х. Котб иҗаты: "Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты курсыннан студентлар өчен уку ярдәмлеге". – Казан, 1976. – 76+3 (факсимиле).
14. Хисамов Н.Ш. XIII–XIV гасырларда Идел буе төрки поэзиясе // Казан утлары. – 1987. – № 4. – 176б.
15. Бертельс Е.Э. Низами. Творческий путь поэта. – М.: Издательство АН СССР, 1956. – С. 101-128
16. Бертельс Е.Э. Литература народов Средней Азии от древнейших времен до XV века н.э. // Новый мир. – 1939. – № 9. – С. 272.
17. Там же.
18. Алиев Г.Ю. Поэма "Хосров и Ширин" Низами Гянджави и одноименная поэма Амир Хосрова Дехлеви: Автореф. дис. … канд. филол. наук. – М., 1957. – 24 с.
19. Алиев Г.Ю. Легенда о Хосрове и Ширин... - С. 232.
20. Бегдели Г. Шәрг әдәбиј̌јатында и "Хосров вә Ширин" мөвзусу. – Бакы: Елм, 1970. – 371 с.
21. Die Kiptschakische Literatur von János Eckmann / Philologiae Türcicae Fundamenta. T. 2. – Wiesbaden, 1964. - 280-285 бб.
22. Хаков В. Тарихи дәреслек өчен / Алтын Урда чоры әдәби теле һәм аның борынгы традицияләре) // Мирас. – 1993. – 3 сан. 72 б.
23. Котби. Хөсрәу – Ширин хикәяте // Мирас. – 1992. – 5 сан. – 31-51 бб.
24. Курбатов Х. Р. Иске татар поэзиясендә тел, стиль һәм строфика. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. – 52 б.
25. Татар поэзиясе антологиясе. 1 китап. – 72-76 бб.
26. Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты: Урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9-нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 1994. – 92-93 бб.
27. Маллаев Н.М. Ўзбек адабиёти тарихи: Университетларнинг филология факультеталри ва педагогика институтларининг тарих-филология факультетлари учун дарслик. Уз ССР Олий ва махсус урта тагълим министрлиги тасдиклаган. Ике китапта. Тошкент: Ўрта ва Олий мактаб. 1963. – Беренче китаб. 307-324 бб.
28. Ўзбек адабиёти тарихи. 5 томда, - Тошкент: Фан, 1977. - 1 т. - 202-221 бб.; Янә кара: Каримов Г., Косимов Б., Мухаммадхўҗаев Х. Куп асрлик адабиёт кузгуси // Шарк юлдузи. 1981. - 9 сан. – 216-218 бб.
29. Фазылов Э. Староузбекский язык. Хорезмейские памятники XIV века. В двух томах. – Ташкент: Фан. 1966. – 1 т. – С. 650.; - 1971. - 2 т. – С. 779.
30. Уч булбул гулшани. – Тошкент: Ғафур Ғулом номидаги адабиёт ва санъат нашриёти, 1986. – 331-619 бб.
31. Хамидов Х. Кутб Хоразмий // Шарк юлдузи. – 1962. – 1 сан. – 116-126 бб.
32. Шарипов Ж.. Кутб Хоразмий ва Сайф Саройининг таржималари хокида // Ўзбек тили вә адабиёти. – 1965. – 2 сан. – 47-53 бб.
33. Эркинов С. Шарк адабиётида Фарход киссаси. – Тошкент: Фан, 1985. – 33-35 бб.
34. Ганиханов М.А. Сравнительный анализ поэм "Хусрав и Ширин" Низами и Кутба; Автореф. дис. …канд. филол. наук. Ташкент, 1994. – 23 б.
35. Валихужаев Б. XV-XIX асрлар ўзбек адабий – танкидий карашлари тарихидан // Фән. хез. җыент. / Ўзбек шегърияти ва адабиётшунослиги тарихидан. Янги серия, 138 – нашр. – Самарканд, 1964. – 47 б.; Маллаев Н.М. Курс. хезм. – 321 б.; Фазылов Э. Староузбекский язык… - 2 т. – 12 б.
36. Таһирҗанов Г. Тарихтан-әдәбиятка... - 105 б.
37. Айдаров Ғ., Құрышжанов Ә., Томанов М. Көне түркі жазба ескерткіштерінің тілі: Университет пен педагогтық институттардың филология факультеттеріне арналган оку куралы. – Алматы: Мектеп, 1971. – 35 б.; Керімов Ә. "Гұлстан"және "Хұсрау мен Шырын" ескерткіштеріндегі –даш- жұрнагы жөнінде // Известия АН Казахской ССР, серия филологическая. – 1976. – 1 сан. – 10-17 бб; Аныкы ук. Кос сөздердің жасулы ("Хұсрау мен Шырын" поэмасының материалы бай - инша) // Известия АН Казахской ССР, серия филологическая. – 1977 – 1 сан. – 43-50 бб.
38. Ибатов А. Кутбның "Хусрау да Шірін" поэмасының сөздігі.– Алматы, 1974. – 278б.
39. Сабиров М.Б. Құтыптың "Хұсрау уа Шырын" поэмасының тіліндегі реликт тұлралар (XIV гасыр): Филол. фән. канд. дис. автореф. - Алматы, 1995. – 22 б.
40. Әмирханов Р. Мәхәббәт фәлсәфәсе чыганагы // Мирас. – 1993. – 5 сан. – 35-41 бб.;

*Татарская социально-философская мысль средневековья (XIII – середина XVI вв.). В двух книгах. 2 книга. – 3-20 бб.*
*41. Госман Х. Алты йөз егерме ел элек // Совет әдәбияты. – 1962. – 12 сан. – 135-137бб.*
*42. Книга рассказов о Хосрове и Ширин (пособия для студентов тюркологов). Фәнни редакторы У. Усманов. 2 дәфтәрдә. – Казан университеты офсет лабораториясе, 1970. – 1 дәфт. – 220 б.; 1971. – 2 дәфт. – 440 б.*
*43. Богынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары: Уку-укыту әсбабы. Казан: Казан университеты нәшрияте, 1981. – 44-143 бб.*
*44. Тексты по старотатарскому языку. Составил А.Фатхиев. Отв. ред. М.Нугманов. – Казань, 1965. – 1-20 бб.*
*45. Islam Ansiklopedisi. – Istanbul: Milli Eğitim basimevi, 1945. – 3т. – 281 б.*
*46. Hacieminoğlu N. Harezm - Kipçak Sahasında Türk Edebiyati // Фән. хезм. җыент. / Türk Dünyasi El kitabi – Ankara: Türk Kültürünü Araştirma Enstitüsü, 1992. – 3 том. 2 басма. – 73 б.*
*47. Исламов Р.Ф. Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни бәйләнешләр. Казан Мәтбугат йорты нәшрияте, 1998. – 41-44 бб.*
*48. Исмаjылова Н. Фирдовсинин "Шаһнамә" вә Низаминин "Хосров вә Ширин" әсәрләриндәки Хосров сурәтләри һаггында // Азәрбаjчан ССР Елмләр академиjасынын хәбәрләри. Әдәбиjат, дил вә инчәсәнәт сериjасы. - 1984. - № 3. – С. 27.*
*49. Nihad Sani Banarlı Resimli Türk edebiyati tarihi, İstanbul, 1948, 107-108 бб.*
*50. Х.Г.Кёр – оглы. Узбекская литература. - М., 1968. – С. 47.*
*51. Урманчеев Ф.И., Надиров И.Н., Мәхмүтов Х.Ш. Фольклор теле – шигърият теле. – Казан: Фикер, 2001. – 12 б.*
*52. Таһирҗанов Г.Т. Тарихтан әдәбиятка. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 96-97 бб.*

**АННОТАЦИЯ**

*Котбның "Хөсрәү вә Ширин" поэмасы әдәбиятта вакытлы күренеш кенә булып калмаган, аның традицияләрен төрки-татар әдәбиятында дәвам иткәннәр. Гуманистик эчтәлекле, югары художстволы бу әсәр бүгенге укучыны да дулкынландыра, аның күңел дөньясын баета. Котб мирасын җентекләп өйрәнү бүгенге көн өчен дә актуаль мәсьәлә.*

*Moukhametzianov Ilias Mullanurovich*

*From history of research of poem "Khosrow and Shirin" by Qutb*

*This historiographical analisis confirms a great interest of scientists to the problems of poem "Hosrow and Shirin" including the regional level. Although some aspects of this problem have been studied enough in historiography in Soviet period they still need further elaboration.*

*Мухаметзянов Ильяс Мулланурович (Казань, Россия) – кандидат филологических наук, старший преподаватель Отделения восточных языков Института иностранных языков Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета (ТГГПУ).*